КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 октябрь г.Казань № 1209

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 3 октябрь, 888 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 3 октябрь, 888 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 19 ноябрь, 1048 нче; 2020 ел, 28 гыйнвар, 33 нче; 2020 ел, 26 февраль, 147 нче; 2020 ел, 27 июль, 626 нчы; 2020 ел, 9 ноябрь, 1002 нче; 2020 ел, 1 декабрь, 1078 нче; 2021 ел, 3 февраль, 52 нче; 2021 ел, 23 апрель, 279 нчы; 2021 ел, 25 сентябрь, 916 нчы; 2022 ел, 17 февраль, 135 нче; 2022 ел, 30 май, 495 нче; 2022 ел, 13 июль, 674 нче; 2022 ел, 26 октябрь, 1143 нче; 2023 ел, 29 март, 370 нче; 2023 ел, 21 июль, 874 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында»

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт программасы) расларга.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгын Татарстан Республикасы дәүләт программасының җаваплы башкаручысы итеп билгеләргә.»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда, мөмкинлекләрне исәпкә алып, һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге максатларга тотыла торган акча чикләрендә Татарстан Республикасы дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыруга акча күздә тотарга.»;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Бу карарга теркәлгән исемлек нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин